Нур бөркүче әбием

«Әтиле кешеләрнең чабаталары да күтәртмәле иде. Шул вакытта андыйларга и-и кызыгып карый торган идек инде. Безгә моны эшләүче булмады, шуңа күрә чәчүлек орлыгы ташыган вакытта чабаталарыбыз инде «чәчәк атар иде».

7 БИТ

Бушлай тикшерен

Күпләр авырый башласалар, узар әле, дип өйдә дәвалана, медицина тикшерүе бик кыйммәткә төшә, чыгымлы дип саный. Баксаң, Татарстанда аны бушлай узу мөмкинлеге дә бар икән. Теркәлү урыны буенча сырхауханәләрдә генә түгел, Татарстанда эшләп килүче махсус сәламәтлек үзәкләрендә тикшеренергә була.

6 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 21.03.2017 | №29 (5791)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ӘТИНЕҢ СҮЗЕ ДӘ, ҮЗЕ ДӘ КИРӘК

Татарстанда һәр бишенче кеше – балигъ булмаган бала. Соңгы елларда республикада дәүләт тарафыннан балалы гаиләләргә аерым игътибар бирелә. Аларның проблемаларын чишүгә юнәлдерелгән проектлар тормышка ашырыла. Татарстанның Хезмәт, социаль яклау һәм эш белән тәэмин итү министрлыгы коллегиясендә балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү турында сөйләштеләр. «Беренче чиратта күп балалы гаиләләр, инвалид балаларга кагылышлы проблемаларга игътибар юнәлтәбез», – ди Татарстанның хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова.

gorodfm.net

Эльвира МОЗАФФАР

1715 БАЛА ӨЙДӘН ЧЫГА АЛМЫЙ

Күп балалы гаиләләр саны елдан-ел арта бара. Әйтик, 2013 елда 24785 өч һәм аннан да күбрәк балалы гаилә исәпләнсә, бүген бу сан 32 меңгә якынлашкан. Бу гаиләләргә торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре өчен түләүләргә субсидияләр, лагерь һәм шифаханәләргә юлламалар бирү, балалар бакчасы һәм мәктәпләрдә туклану белән тәэмин итү кебек социаль ярдәмнәр каралган. Күп балалы гаиләләргә торак төзү өчен җир кишәрлекләре бирү буенча да Татарстан – Идел буе федераль округында беренче урында.

Инвалидлыкка килгәндә, республикада физик яктан мөмкинлеге чикле 15 мең бала исәпләнә.

– Кызганыч, аларның 1700е бүген бөтенләй өйдән чыга алмый. Аларны тормыш шартларына җайлаштыру, талантларын үстерү өчен төрле чаралар күрелә. Гаиләләрдә булып, инвалид балаларның әти-әниләре белән эш алып барыла. Сабыйларның белем алуларына игътибар бирелә. Укыта белмәгән белгечләр буладыр бәлки, әмма укый алмаган бала юк – һәрбер сабый талантлы. Нәтиҗәләр дә юк түгел, элек мәктәпләргә, балалар бакчаларына физик яктан мөмкинлеге чикле бер-ике бала килсә, хәзер махсус инклюзив төркемнәр эшли. Инвалид балалар, сәламәт яшьтәшләре кебек, тигез дәрәҗәдә белем ала, – ди министр.

Татарстанда физик яктан мөмкинлеге чикле балалар өчен 13 тернәкләндерү үзәге эшләп килә. Анда медицина ярдәме күрсәтү, комплексы тернәкләндерү белән берләштән балаларны төрле күнекмәләргә өйрәтергә, укыту, һөнәр сайлау буенча киңәшләр бирергә дә тырышалар. Былтыр гына да бу үзәкләрдә 6 меңнән артык бала тернәкләнү узган.

–Балаларның бу тормышка җайлашулары, әйтик, даруханәгә барып үзенә кирәкле даруны алу, кибеттән ризык алып кайту кебек гади генә күнекмәләргә өйрәнүе мөһим, чөнки киләчәктә аларның әти-әниләре олыгая. Ярдәмчесез калмас өчен, инвалидларга юридик, социаль, педагогик ярдәмне вакытында күрсәтергә тиешбез, – дип саный Эльмира Зарипова.

ЧЫБЫК ТА ҮРӘ, ЧӘЧӘК ТӘ ЯСЫЙ

Тернәкләндерү үзәкләрендә инвалид балалар белән эшләүдә яңа алым – хезмәткә өйрәтә башлаганнар. Бу өлкәдә тернәкләндерү оешмалары мәшгульлек үзәкләре белән тыгыз элемтәдә эшли.

→ **Ахыры 2нче биттә.**

ШӘҺӘР ХУҖАЛЫГЫ

Артыгын кыланмагыз: ишегаллары видеокүзәтүдә

Татарстан башкаласында хәзер йортлар һәм мәктәпләр тирәсенә чүп ташлаучыларны, кече архитектура корылмаларын ватучыларны, автомобильне урлап китәргә маташучыларны «койрыкларыннан» гына эләктереп алачаклар.

Автор фотосы

Мәгълүмати технологияләрне һәм элемтәне үстерү буенча 2017-2019 елларга исәпләнелгән «Электрон Казан» программасын гамәлгә ашыру башланды.

– Казанда 1270 йорт 4330 видеокамера ярдәмендә күзәтү астына алынган инде. Быел 2000 йортка, ә «Имин шәһәр» проекты кысаларында барлыгы 4143 күпфатирлы йортка видеокамера куелачак. Видеоҗиһазлар урнаштырган өчен, торак милекчеләреннән түләү алынмый, – диде шәһәр башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр һәм элемтә идарәсе җитәкчесе Рифат Ханнанов кичә «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә.

Программага 561,6 миллион сум билгеләнгән. Әлеге акчаның 449 миллион сумы – шәһәр бюджетыннан, калган өлеше – республика һәм инвесторлар чыганаклары. Бюджет беренче чиратта мәктәпләрне, балалар бакчаларын һәм башка социаль учреждениеләрне видеокамералар белән җиһазлауга тотыла.

Йортны яхшы күзәтчелектә тоту өчен кимендә – 3, ә иң күбе 16 видеокамера кирәк. Бер видеокамера хезмәте аена 600 сумга төшә.

– Күпфатирлы гадәти йортлар, торак-төзелеш ширкәтләре, кооператив йортлар милекчеләре ничә видеокамера куюны, соңыннан хезмәт күрсәтүгә түләү тәртибен гомумҗыелышта үзләре хәл итәләр. Әйткәнемчә, видеокамералар урнаштыру өчен түләү алынмый, бу эшләр бюджет хисабыннан башкарыла. Кешеләр автомәйданчыкларга, подъездларга берничә камера куярга теләргә мөмкин, – диде Рифат Ханнанов.

Шәһәр башкарма комитеты инде хәзер дә муниципаль хезмәтләрнең 11 төрен электрон рәвештә күрсәтә. Шулардан иң активлары: ЗАГСта никахны, туу һәм үлем фактын теркәү, торак ихтыяҗы чиратына басу, торак мәйданны үзгәртеп планлаштыруны раслау, торак мәйданны – торак булмаган яки торак булмаган мәйданны торакка әйләндерү. Быел сабыйларның балалар бакчаларына кабул ителүен, шулай ук архив белешмәләрен һәм документлар күчермәләрен бирүне электрон тәртиптә башкаруга күчү ниятләнелә.

Казанда муниципаль учреждениеләргә мөрәҗәгать иткәндә, «электрон чират» сервисы тагын да киңрәк кулланышка кертеләчәк. Киров һәм Мәскәү районнары хакимиятендә бу алым инде 2016 елның март аеннан гамәлдә.

Мэр Илсур Метшин, үзенең фикерләре белән уртаклашканда, мәгълүмати технологияләрнең зур әһәмияткә ия булуын әйтте. Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсендә электрон рәвештә хезмәт күрсәтүнең куелышын аерым игътибарга алырга чакырды.

Дамир БӘДРИЕВ.

Казаннан Петербургка туры юл

27 марттан Казан – Санкт-Петербург шәһәрләре арасында туры һава юлы ачыла. Самолетлар ике якка атнасына алтышар тапкыр очачак. Беренче рейсларга билетлар инде сатыла башлаган. Бер якка минималь билет бәясе – 2800 сум. Бу бәядә әле ягулык өчен киткән чыгымнар каралмаган.

«Алабуга» импортны алмаштыра

Алабуга махсус икътисади зонасының «Кастамону интегрейтед вуд индастри» оешмасы заводы Россиядә «Импортны алыштыручы иң яхшы проект» исеменә лаек булды. Әлеге дәрәҗәле исемне Россия Сәнәгатьчеләр һәм эшкуарлар берлеге президенты Александр Шохин үз кулы белән завод директоры Али Кылычка тапшырды.

Төркиянең «Кастамону» компаниясенең Алабугадагы заводы 2011 елда төзелә башлады. Ул МДФ-панельләр җитештерә.

– Бүген җитештерелгән продукциянең 60 проценты бары Россиядә генә кулланыла. Продукция көнбатыш чикләрдән алып Ерак Көнчыгышка кадәр булган чимал кытлыгын киметә, – диде Али Кылыч.

Әтинең сүзе дә, үзе дә кирәк

→ Ахыры. Башы 1нче биттә.

Кукмара районы «Шәфкать» тернәкләндерү үзәге 2004 елда 200 мең сум грант отып, шул акчага һөнәрчелек өчен кирәкле эш кораллары, җайланмалар сатып алган. Хәзер биредә физик яктан мөмкинлекләре чикле балалар чигә, тегә, агачтан төрле эшләнмәләр ясый, аш-су серләренә төшенә, яшелчә, җиләк-җимеш үстерергә өйрәнә. Бу эштә районның эшмәкәрләре дә теләп булыша. Әйтик, шәхси эшмәкәр Язилә Гарифуллина балаларга үзенең пекарнясында ипинең ничек пешерелгәнен күрсәткән.

– Инвалид балалар, әниләре белән бергә, капроннан чәчәкләр ясарга өйрәнәләр. Бер әни декрет ялында шул чәчәкләрне ясарга остарып китте дә үзенең кул эшләнмәләреннән күргәзмә оештырды, кайбер эшләрен сатып, акча эшләде. Хәзер үзе дә, «Шәфкать» тернәкләндерү үзәгенә килеп, мастер-класслар уздыра, – ди үзәкнең җитәкчесе Роза Фазлыева.

Былтыр биредә 35ләп инвалид бала талчыбыктан әйберләр үрергә өйрәнгән. Болар барысы да балага җәмгыятьтә югалып калмаска, һөнәрле булырга ярдәм итә. Шул ук вакытта үзәк төрле предприятие-оешмалар белән килешүләр төзеп, үзендә хезмәт күнекмәсе алучыларны эшле итә. Мәсәлән, аларның кайсысы Кукмара тегү фабрикасына урнашкан, кайсы мәдәният йортында тавыш куючы булып эшли, берсе үз кинематография студиясен ачкан. Инвалидлар арбасында утырган бер кыз такси хезмәтенә диспетчер булып урнашкан.

ПРИЮТЛАР ТИКШЕРЕЛӘЧӘК

Имин булмаган гаиләләр белән эш алып бару – мөһим тармакның берсе. Республикада барлыгы шундый 1268 гаилә исәпләнә. Бу мәсьәләдә Татарстанның кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Сәрия Сабурская колонияләрдән кайтачак, тиздән азат ителәчәк үсмерләр белән җитди эш алып барырга кирәклегенә басым ясады. Һәр район башлыгыннан бу балаларны фамилияләп белергә, аларны эш белән тәэмин итү, торак мәсьәләсендә булышлык күрсәтүне дә сорады. Быел республикада 41 балигъ булмаган үсмер тәрбия колонияләреннән үз өйләренә кайтачак.

– Бу үсмерләргә кешечә, нормаль яшәргә мөмкинлек бирегез. Тормыш авырлыклары аркасында, алар кабат элеккеге юлга басмасыннар иде, – диде Сәрия Сабурская.

Татарстан Дәүләт Советы рәисе урынбасары Татьяна Ларионова залда утыручыларны, видео режимында коллегияне күзәткән район вәкилләрен дә «кызырып» алды. Инвалид балаларның төрле түгәрәкләрдә аз шөгыльләнүен искәртте ул.

– Ни өчен Түбән Камада балаларның түгәрәкләргә йөрү дәрәҗәсе бары 4 процент белән генә чикләнә? Югыйсә, Түбән Кама инвалид балалар белән эшләүдә үрнәк күрсәткән беренче шәһәр иде. Хәзер киресенчә. Апас, Менделеевскида бу күрсәткеч – 0,5 процент. Сездә түгәрәкләр юкмы? Бу саннарны әйтергә дә оят, – дип ассызыклады җитәкче.

Татьяна Ларионова приют эшчәнлекләрен дә җентекләп тикшерергә сүз бирде. Апрель аенда Әгерҗе, Менделеевск районнарында Попечительләр советының киңәйтелгән утырышы узачак. «Бергә булдырабыз» дип аталган республика проекты кысаларында, приютлардагы эшчәнлек белән танышачаклар.

Имин булмаган гаиләләрнең кабаттан күзәтү астына алынуы Татьяна Ларионованы да, Эльмира Зариповaны да гаҗәпләндерде дә, борчуга да салды.

– Казан никадәр зур булмасын, нибары бер генә гаилә кабат күзәтү астына алынган, ә Чаллыда шундый 16 гаилә исәпләнә. Социаль яклау, балигъ булмаганнар белән эшләү комиссиясенең күзәтүе астына алынган балалар белән җитди эш алып барырга, бу гаиләнең проблемаларын җентекләп чишәргә кирәк, – диде Татьяна Ларионова.

Коллегиядә балаларны тәрбияләүдә Әтиләр советының катнашуы да кирәк дип нәтиҗә ясалды. Бу хакта Дәүләт Советы депутат хатын-кызларының «Мәрхәмәт-Милосердие» оешмасы Татарстан Президентына да мөрәҗәгать иткән булган. Рөстәм Миңнеханов бу фикерне хуплаган. Ни дисәң дә, балага әти сүзе, ир-ат тәрбиясе кирәк шул.

Алмаз Хәмидуллин – кабат җиңүче

«Казан шәһәренең ел укытучысы – 2017» бәйгесенең абсолют җиңүчесе Алмаз Хәмидуллин Бөтенроссия «Ел укытучысы – 2017» бәйгесенең төбәк этабында да иң яхшысы дип табылды. Республика бәйгесе йомгакларын Казанның 177нче мәктәбендә ясадылар.

Алмаз Хәмидуллин – Казан шәһәренең Мәскәү районындагы 2нче лицей-интернатның математика укытучысы. Элек ул Түбән Кама мәктәбендә эшләгән, агымдагы уку елында Казанга күченеп килгән. Алмазның педагоглык стажы – алты ел.

– Бәйге сынауларын үткән айларда мин һөнәри яктан һәм шәхес буларак үстем. Әлеге югга басканда, бу кадәр үк кыен булыр дип уйламаган идем. Бөтенроссия бәйгесендә Татарстанны лаеклы күрсәтә алырмын дип ышанам. Бу бик зур җаваплылык, – ди ул.

Казан шәһәре мәгариф идарәсе җитәкчесе Илсур Һадиуллин сүзләренчә, соңгы өч елда «Ел укытучысы» конкурсында җиңүчеләрнең саны өч тапкырга арткан.

– Казан укытучылары өч мәртәбә абсолют җиңүче дип табылды һәм Бөтенроссия бәйгесендә Татарстан данын якладылар, – диде ул эшлекле дүшәмбедә.

ИГЪТИБАР!

Юридик белешмә – бушлай

Быелның 24 мартында Бөтенроссия халыкка бушлай юридик ярдәм көне үткәрелә. Бу чара «Россия юристлары ассоциациясе» тарафыннан оештырыла.

Татарстанда 24 март көнне бушлай юридик ярдәм Россия Федерациясе Президентының кабул итү бүлмәсендә, «Бердәм Россия» партиясе рәисенең төбәк җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәсендә, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасында, «Бердәм Россия» партиясенең район (шәһәр) бүлекләренең кабул итү бүлмәләрендә күрсәтелә. Россия юристлары ассоциациясенең Татарстан төбәк бүлегенең Казандагы, Әлмәттәге һәм Бөгелмәдәге халыкка бушлай юридик ярдәм күрсәтү үзәкләренә дә килергә була. Кабул итү Казанда 9.00-17.00, ә районнарда һәм башка шәһәрләрдә 8.00-16.00 сәгатьләрдә.

Сорауларга җавапларны Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы, Прокуратура, Конституция суды, суд приставлары федераль хезмәте, адвокатлар, нотариуслар, Россия юристлары ассоциациясе юристлары бирә.

Казандагы кабул итү бүлмәләре адресларын **Shahrikazan.com** сайтыннан, «Бердәм Россия» партиясенең башка районнардагы җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәләренең адресларын Россия юристлары ассоциациясе Татарстан төбәк бүлегенең сайтыннан карарга була: **alrf16.ru.** Белешмәләр өчен телефон – **(843) 223-07-83.**

Лагерьлар кышкы салкыннарда өшемәячәк

ru-kurort.ru

ҖӘЙНЕ КӨТКӘНДӘ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 2014 елда балаларның җәйге сәламәтләндерү лагерьларын караган вакытта, монда да программасыз булмый икән, дигән.

– Президент башлангычында 2014 елда ук республика бюджетыннан 100 миллион сум акча күчерелде. Әлеге чыганакларга 13 лагерь капиталь төзекләндерелде, – дип искә төшерде республиканың төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары Алексей Фролов «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә.

Программа кысаларында, 2015 елны – 14, ә узган ел тугыз лагерь капиталь ремонтланган. Быел Зәйдәге «Созвездие», Бөгелмәдәге «Яблочко», Ютазыдагы «Дубравушка» һәм Әгерҗедәге «Алмалы» комплексы яңартыла. Өч лагерьга реконструкция, ягъни үзгәртеп төзү үткәрелә. Әгерҗе, Бөгелмә, Спас һәм Яшел Үзән муниципаль районнарында балалар өчен яңа лагерь комплекслары төзелә.

– Республикадагы элеккеге пионер лагерьлары Совет чорында 1960-70 елларда сафка баскан. Корылмалар инде бик нык тузган. Кышкы айларда ягылмау сәбәпле, биналар тагын да тизрәк искерә. Моны чикләү максатында, корпусларны җылылык челтәре белән төзи башладык, – ди Алексей Фролов.

Казанның Киров районындагы «Заречье» балалар лагере корпуслары, мәсәлән, җылылык челтәре белән тәэмин ителгәнлектән, ел әйләнәсендә файдалану мөмкинлеге бар. Башкаладагы муниципаль карамактагы 15 лагерь төзекләндерелә.

– Республика буенча лагерьларда төзү-монтаж эшләрен 1 майга тәмамлау бурычы куелды. Лагерьлар балалар килүгә әзер булырга тиеш, – ди Алексей Фролов.

Казанда узган җәйдә шәһәр яны лагерьларында 28 мең бала ял иткән.

– Татарстанда 80 лагерь исәпләнә, 2014-2016 елларда шуның 36сы капиталь ремонтланды. Балалар сәламәтләндерү лагерьларына ихтыяҗ бар, төзекләндерү эшләре дәвам итәчәк, – дип өметләндерде Алексей Фролов.

Дамир БӘДРИЕВ.

Быелдан пенсия өлкәсендәге кызыксындырган сорауларны Telegram мессенджеры аша да юлларга мөмкин. Ике ай эчендә шул рәвешле 100 сорау кабул ителгән.

Пенсия «Телеграм»да

Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге соңгы елларда гражданнар белән Twitter, Facebook һәм «ВКонтакте» социаль челтәрендә актив эш алып бара. Быел фонд YouTuBe та үз каналын да булдырган. Белгечләр бер ел эчендә социаль челтәрләр аша 1000гә якын сорауга җавап биргәннәр, алар интернет аша онлайн консультацияләр бирә, пенсия өлкәсендәге соңгы яңалыклар белән таныштырып бара, шикаять, теләк, үтенечләрне дә интернет аша кабул итә.

– Соңгы арада төрле яшьтәге кешеләр интернет челтәрләрдән актив куллана. Шуңа да Пенсия фонды интернет чыганакны республика халкына якынрак булу өчен файдаланырга булды. Бу үзара элемтәне җайлаштыра, – ди Татарстанның пенсия бүлеге җитәкчесе Эдуард Вафин.

Telegram мессенджеры аша белгечләргә сорау бирер өчен, әлеге кушымтаны телефонга яки компьютерга урнаштырып, **+7(927)419-27-27** телефонына сорау юлларга кирәк. Пенсия бүлеге җитәкчеләре җавапларны мөмкин булган кадәр кыска вакыт эчендә әзерләячәк.

Электрон чират популярлаша

Медицина өлкәсендә еш яңгыраган проблемаларның берсе – тиешле белгечләргә эләгә алмау. Табиб ишегә төбендә, гадәттә, су буе чират. Бу мәсьәләне хәл итү максатында, электрон чиратны уйлап таптылар.

Хәзер табибка Татарстанның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, электрон чират терминаллары, «Электрон Татарстан» инфоматлары, мобиль кушымта аша да язылырга мөмкин. Тәҗрибә күрсәткәнчә, кешеләр күбесенчә электрон чират терминалыннан файдалана икән. Бу хакта Татарстанның Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы хәбәр итә.

Әйтик, Республика клиник онкологик диспансерында лаборатор һәм диагностик тикшерүләргә быелның ике аенда гына да 320 мең тапкыр язылганнар. Табибка электрон язылу халык арасында иң кирәкле хезмәтләрдән санала. Былтыр республикада бу хезмәттән 11,4 миллион тапкыр файдаланганнар.

Казан шәһәре башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе, әнисе

Рамилә Зәки кызы МӘХМҮТОВА

вафат булу сәбәпле, администрация башлыгы урынбасары Мәхмүтов Марат Рәшит улының, туганнарының, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Мәрхүмәнең авыр туфрагы җиңел булсын.

КОРЫЛТАЙ АЛДЫННАН

Татарстан халыкларының III съездына әзерлек дәвам итә. Әлеге уңайдан республика районнарында делегатлар сайлана. Гадәттә, мондый зур җыеннарда нинди дә булса яңа фикерләр ишетәсең, киләчәккә максатлар куясың. Делегатлар бу турыда үзләре ни уйлый?

Леонид САПОЖНИКОВ, Балтач районының удмурт оешмасы рәисе:

– Без, съездга бару өчен, делегатларны сайладык. Барысы биш кеше барачак. Анда үзебезне борчыган мәсьәләләргә җавап ишетергә өметләнәбез, теләк-тәкъдимнәребезне дә җиткерергә уйлыйбыз. Республикада яшәүче удмуртлар өчен газета чыгуын телибез. «ТНВ» телеканалында угро-фин халыклары турында даими тапшыру эшләнсен иде. Аннары, 1997 елдан бирле тупланып килгән материалларымны җыеп, «Сокровища удмуртского фольклора» дигән тарихи-документаль китабымны чыгарасым килә. Аңа да грант формасында ярдәм алып булмасмы дигән өметем бар. Безне ишетерләр дип уйлыйм.

Роза ГАТАУЛЛИНА, Зәй районының Милли мәдәният үзәге җитәкчесе:

– Милли мәдәният үзәге җитәкчесе буларак, мине гаилә кыйммәтләрен саклап калуның заманча ысуллары кызыксындыра. Тел, традиция, гореф-гадәтләр, йолалар иң беренче нәүбәттә гаиләдә саклана. Әлеге проблема бүген бөтен милләт кешесен борчый. Шушы мәсьәләдә башкаларның эш тәҗрибәсен өйрәнәсебез килә. Үзебезнең эшне дә күрсәтү теләге бар. Без даими рәвештә «Зирәклек дәресләре» үткәреп киләбез. Очрашуга төрле милләтнең абруйлы вәкилләрен, лидерларын чакырабыз. Балалар бакчаларында, мәктәпләрдә, мәдәният йортларында төрле милли бәйрәмнәр уздырыла. Май чабуны да, Карга боткасын да, Нәүрүзне дә бәйрәм итми калганыбыз юк. Уенын-чыны кушып әйткәндә, съездга үзебезне дә күрсәтергә, башкаларны да карарга барабыз.

ТАТАРСТАН ХАЛЫКЛАРЫ

Әбисенең чәчләрен каралткан бурят кызы

Бурятия белән Казан арасы 5 мең километр булса да, үзләренә яшәү урыны итеп Татарстанны сайлаган бурятлар бар. Алар башкалабызда иң аз санлы халыклардан санала, нибары 150 кеше. Узган ел бурятлар үзләренең милли-мәдәни автономияләрен оештырганнар. Без аның җитәкчесе Сэсэгма Бубеева белән очрашып, бурят халкының яшәеше, аларның гореф-гадәтләре белән кызыксындык.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

– Сэсэгма Викторовна, Сез – бурят авылында туып-үскән кеше. Бурятларның үзенчәлекләре, аларның нәрсә белән шөгыльләнүе хакында сөйләгез әле.

– Бурят авыллары мондагы кебек дияргә була, әмма читтәрәк аерым хуҗалыклар булып хайван асрап яшәүчеләр бар. Бурят халкы элек-электән ат, сыер, сарык асрап көн күрә. Бездә ат изге хайван санала, аның итен ашамыйлар. Безнең халык беркайчан да җир эшкәртү, утырту эшләре белән шөгыльләнмәгән. Тора-бара ул кәсеп Россиядән керә башлады. Заманында минем әбиемнең күршесендә татар гаиләсе яшәгән. Аның сөйләвенчә, кечкенә чакта күрше хатыны әбине бакчада яшелчәләр үстерергә, кичләрен тегәргә, бәйләргә, чигәргә өйрәткән. Ул һөнәрләре аңа тормышта зур ярдәм иткән. Шуның өчен 85 яшьлек әбием күршесенә бүгенге көнгә хәтле рәхмәтле.

– Татарстанга нинди җилләр ташлады үзегезне? Казан кай ягы белән җәлеп итте?

– Без башта гаиләбез белән Мәскәүгә килгән идек. Аннары Казанны күрергә дип килсәк, ирем шунда ук монда калырга теләк белдерде. Безне биредә кешеләрнең ярдәмчеллеге җәлеп итте. Автобуста барганда, шәһәрдәге берәр урынны сорасаң, пассажирларның һәркайсы ярдәм итәргә тора.

– Татарлар белән бурятларның телендә, холкында, мәдәниятендә охшашлыклар күрәсезме?

– Татарларга да безнең халыклар сыман җылылык, гадилек хас. Безнең батыр, Булат, алтын һ. б. шактый гына сүзләребез уртак. Татар халык көйләренең дә охшашлары бар. Аш-суга килгәндә, сездәге сыман өйдә басылган токмач, буузы (сездәге манты кебек) милли ризыгыбыз санала. Сөт ризыкларын яратабыз. Охшаш бәйрәмнәребез дә бар. Җәй көне ел саен татар халкының Сабан туена охшаган бәйрәм үткәрәбез. Анда көрәш, ат чабышлары, аркан тартышу һәм башка уеннар уртак. Бездә сөңгедән ату гына аерыла. Яңа ел кышның төрле вакытына күчәргә мөмкин. Мәсәлән, быел без аны 28 февральдә үткәрдек, киләсе елда 16 февральдә булачак. (Ай календаре буенча күчә.)

– Сезне бурятларның яңа оешкан милли-мәдәни автономиясенең җитәкчесе итеп сайлаганнар. Һөнәрегез буенча кем Сез?

– Мин Улан-Удэдагы университетта бурят теле белгечләре алып чыктым. Аннан соң мәктәптә җиде ел бурят теле укыттым. Биредә Көнчыгыш медицинасы үзәге директоры булып эшлим. Клиникада үзем дәвалаамыйм. Бу бездә нәселдән килгән. Махсус белем булмаганлыктан, массаж белән өйдәгеләрне генә дәвалыйм. Минем әбием авылда танылган дәвалаучы иде. Үзе фельдшер булып эшләде. Аның әнисе дә кешеләрне дәвалаган.

– Әбиегездән аның дәвалау алымнарын үзләштерергә каласыгыз килмиме?

– Ул бик авыр хезмәт. Мин аны балачактан ук аңладым. Әбигә 50 яшь чагында инсульт булып, сул ягы бөтенләй эшләми башлады. Шул чакта ул миңа үзенең уч төбендәге аерым нокталарга массаж ясарга өйрәтте. Көн саен аңа карандаш белән массаж ясап дәваладым. Шуннан соң аяк-куллары йөри башлады, хәтта агарган чәчләре дә каралды.

– Бурятларда шаманнар да дәвалый. Аларга мөнәсәбәтегез?

– Буддо дине кабул ителгәнче, бурятларда шаманлык булган. Бездә хәзер дә шаманнар бар. Алар нәселдән килгән бозымнарны, гөнаһларны алалар, дәвалыйлар. Шаманнар үз белемнәрен балаларына калдырмый, ләкин ул барыбер кабатлана.

– Казанда буддо дине әһелләренә үз диннәрен тоту мөмкинлеге бармы?

– Калмыклар, алтайлылар, монголлар – барысы да буддо динендә. Әле күптән түгел генә үзебездә югары белем алган дин әһеле Гармажаб ламаны чакырып китердек. Үз дини йортыбыз булыр дип өметләнәбез, чөнки Татарстанда башка халыкларны да хөрмәт итәләр.

– Казанда яратып йөри торган урыныгыз бармы?

– Шәһәрдә матур урыннар бик күп. Ә Казан гаилә үзәге янына бөтен бурятлар да яратып йөри, чөнки ул бурят скульпторы Даши Намдаков проекты буенча төзелгән. Аның эшләре Президент Рөстәм Миңнехановка да ошаган.

Террорчылык ул – афәт

Казан илкүләм тикшеренү технология университетында терроризм һәм экстремизмга каршы тору темасына «Тынычлык территориясе» дигән кейс-чемпионат узды. Студентлар арасында мондый юнәлештәге түгәрәк өстәлләрне «Татарстан иҗади яшьләр академиясе» берләшмәсе Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән берлектә оештыра.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Узган елны без әлеге чараны башка форматта уздырдык – экспертлар чакырдык. Алар студентларга лекцияләр укыды. Быел исә студентларның үзләрен тыңларга булдык. Аларны биш төркемгә бүлеп, һәркайсына фикер алышу өчен берәр тема бирдек, – дип сөйләде безгә Терроризм һәм экстремизм буенча республика яшьләр программасы җитәкчесе Сабина Вафина.

Яшьләр «Интернет челтәрендә терроризм», «Халык арасында ыгы-зыгыны бетерү», «Террористларны вербовкалау», «Наркотрафикка каршы тору», «Террор характерындагы ялган хәбәрләр» темасына фикер алышты, терроризм һәм экстремизм идеяләре таралуга каршы көрәш ысуллары турында сөйләштеләр.

Түгәрәк өстәлгә эксперт буларак Татарстанда терроризмга каршы комиссия аппараты җитәкчесе Илдар Галиев тә чакырылган иде. Ул билгеләп үткәнчә, экстремизмга һәм терроризмга каршы көрәш максатыннан, яшьләр арасында бу афәтләрне кисәтү эшчәнлеген даими алып бару сорала.

– Экстремистлар яшьләрне киләчәкләреннән мәхрүм итә, алар да алдагы көннәренә өмет-ышанычларын бетерү өстендә эшли. Яшьләрне экстремистик оешмаларга җәлеп итү алар өчен ансатрак. Димәк, яшь буын үзен алардан сакларга тиеш. Террорчылык ул – кешелекне юкка чыгаручы афәт, – диде ул.

Шулай ук эксперт буларак чакырылган Татарстан Фәннәр академиясенең Исламны өйрәнү үзәге хезмәткәре Валерий Горшунов фикеренчә, яшьләр арасында экстремизм һәм терроризм идеяләрен таратуда интернет челтәренең тискәре йогынтысы зур.

– Укымаган, эшсез йөргән, кесәсендә акчасы булмаган, башка социаль проблемаларын хәл итә алмаган, җәмгыятьнең үзенә карата тискәре карашын сизгән яшьләр көннәрен интернетта уздыра. Төрле радикаль оешма әгъзалары андыйларны социаль челтәрләрдән эзләп кенә утыра. Башкаларга үзен кирәкмәгән дип санаучылар анда үзләренә «иптәш» тә таба. Шуннан радикаль оешмаларга да кереп китә, – ди ул.

Валерий Горшунов соңгы вакытта балалар арасында киң таралган, аларны үз-үзләренә кул салуга этәргән «Зәңгәр кит» интернет-уенын да искә алды.

– Мондый уеннарга каршы тору өчен дәүләт югарылыгында нинди дер бер позитив кызыклы уен уйлап чыгарырга кирәк, – ди ул.

Урау юллар аша биеклеккә

Күренекле композитор, педагог, Татарстанның халык артисты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әнвәр Шәрәфиев – музыка сәнгатенең традицияләрен саклап, аның үсешенә үзеннән зур өлеш керткән шәхесләрнең берсе.

Әнвәр Шәрәфиевне әлеге олы бүләккә, төрле елларда дөнья күргән «Сандугачкай» (балалар һәм яшүсмерләр өчен фортепиано пьесалары җыентыгы), «Чулпан йолдыз» (балалар һәм яшүсмерләр өчен җырлар җыентыгы), «Наз» (скрипка пьесалары һәм пьесалар) китаплары өчен, Татарстан Республикасының Композиторлар берлеге тәкъдим итә.

Әнвәр Шәрәфиевнең гомер юлы тигез генә бармый, сикәлтәләр аша узарга туры килә аңа.

Ул Тымытык районының (хәзерге Азнакай) Урсай авылында җиде балалы ярлы крестьян гаиләсендә туа. Апа-абыйлары авылда эшли башлап, ачлы-туклы көн күрүдән арынып, җайга салына башлаган тормышлары җимерелә: илдә сугыш башлана. Әтисе белән апасы сугышка киткәч, сигез яшен дә тутырмаган Әнвәрне авыл көтүен көтәргә куялар.

Менә шул вакыттан алып табигатьнең тылсымлы көче Әнвәрнең сәләтен ачарга бер сәбәп булгандырмы, ул, абыйсының иске гармунын кулына алып, үзлегеннән уйнарга өйрәнә.

– Шул мизгелләрдә үзем дә аңламаган сихри көч күңелемне яулап алды, музыкага омтылышым уянды, – дип елмаеп куя Әнвәр.

Әмма җиз телләргә яки бака-төймәләргә җиңелчә кагылып китү белән үк сихри моң чыгару һәркемгә дә бирелмәгән. Бу инде табигатьтән килгән бер могҗиза.

Тора-бара ул авылда танылган гармунчы була. Район олимпиадаларында катнашып, алдынгы урыннарны яулый. Тормыш авырлыгыннанмы, 1947 елны 12 яшен дә тутырмаган Әнвәр, әнисенә дә әйтмичә, өйдән чыгып китә. Свердловск шәһәренә барып чыга. Әнвәрне милиционерлар тотып, үзе кебек берничә үксез белән бергә, балалар йортына тапшыралар. Ни гаҗәп, шул балалар йортында аңа иҗат юлында киң мөмкинлекләр ачыла. Бер генә концерт та Әнвәрнең катнашыннан башка узмый.«Тормыш университетлары»н узган Әнвәр инде аңлы рәвештә үзенә профессиональ музыкант булу максатын куя. Тырышып укый. 1953 елны 7нче сыйныфны «бишле» билгеләренә генә тәмамлый. Аны Алабуга мәдәни-агарту училищесына укырга җибәрәләр. Җырлар иҗат итә башлау да шул чорга туры килә. Аның җырларын танылган композитор Әнвәр Бакиров тыңлап, уңай бәя бирә һәм укырга киңәш итә.

1956 елны Әнвәр Казан музыка училищесына укырга керә. Анда укыган елларында ук аның җырлары халык арасына чыга, республика газеталарында басыла башлый. Соңгы курста укыганда, «Лирик җырлар» дип аталган китабы дөнья күрә.

Берничә дистә җыр, инструменталь пьесалар авторы Әнвәр Шәрәфиев музыка училищесын тәмамлап, 1960 елны Казан консерваториясенә укырга керә.

Әйтергә кирәк, бары тик сәнгатькә булган олы мәхәббәт, үз-үзенә ышанучанлык кебек күркәм сыйфатлар гына Әнвәр Шәрәфиевне зур иҗат юлына алып чыга.

1966 елда ул Казан дәүләт консерваториясендә композиция буенча профессор Альберт Леманда, оркестровкадан композитор Нәҗиб Җиһановта төпле белем алып, зур сәнгать юлына баса, профессиональ әзерлегенең яңа дәрәҗәсен билгели. Әмма профессиональ музыка дөньясында үз кыйбласын табуы җиңел булмый. Алай да, нинди генә каршылыклар очрамасын, алар Әнвәрнең рухын ныгыта гына бара, иҗатына тугры терәк була.

Татарстанның халык артисты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әнвәр Шәрәфиев менә инде 50 елдан артык иҗат итә, тыңлаучыларны үзенең ихласлыгы, тирән лирик әсәрләре белән сокландыруын дәвам итә. Ә Шәрәфиевнең бихисап вокаль һәм инструменталь әсәрләре халкыбызда танылу алды.

Иҗатындагы төрле инструменталь һәм вокаль әсәрләре, симфоник («Юллар», «Риваять») поэмалары, камера музыкасы, скрипка һәм фортепиано өчен поэмалары (җыр-романслар, зур булмаган инструменталь пьесалар) – һәркайсы җылы, якты, лирик хисләр белән сугарылган. Аларда халкыбыз моңы аермачык.

Ул – профессиональ милли музыка сәнгатендә үз темасын, телен, кыйбласын тапкан автор. Гомумән, бу моң иясе халык музыкасын искиткеч яхшы белә һәм халык телендә гаҗәеп ихлас яңгырашлы, яңа аһәңнәргә бай әсәрләр иҗат итә.

Композиторның әсәрләре Татарстан, дөнья күләмендәге фестивальләрдә башкарылалар. Әйтик, композиторның скрипка һәм фортепиано өчен язылган «Сүзсез җыр» исемле әсәре Санкт-Петербургта узган «Петербургская музыкальная весна» халыкара музыка фестивалендә башкарыла. Казанда узган «Төрек дөньясы» дигән беренче халыкара музыка фестивалендә скрипка һәм фортепиано өчен «Триптих»ы яңгырады. Әнвәр Шәрәфиев, Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап, байтак инструменталь һәм вокаль әсәрләр иҗат итте: «Гармун уйный берәү», «Арабызга кайталар» җырлары шундыйлардан.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТ

Композитор үзенең иҗатында, беренчеләрдән булып, музыкада ятимлек темасын күтәрә. Хәзерге вакытта бу тема бик актуаль. Ятимлек ачысы бәгырьләргә үтәрлек итеп сурәтләнгән җыр – композитор Мидхәт Миншин сүзләренә язылган «Нигә мин ятим?» җырын исә тыныч кына тыңлап булмый. Әйе, тормышның һәр мизгелен, табигатьнең серле яшәешен, кешеләр күңелен нечкә йөрәгең аша үткәреп музыка телендә әйтә алу – зур бәхет ул.

Әнвәр Шәрәфинең кайсы гына җырын, хәтта төрле уен кораллары өчен язылган әсәрләрен алма, алар табигыйлеге, аһәңле һәм моңлы булуы белән аерылып тора.

Халык тарихын тирән тоюы, аны йөрәге аша кичерүе, шундагы образларның хәленә керүе, халыкның үткәнен һәм эчке дөньясын аңлап иҗат итүе композиторның әсәрләрен татар музыка сәнгатендә югары урынга куя. Композиторның иҗади сәләте һәм рәссамнарча фикерләү-кузаллавы көче белән әсәрләрендә халык тормышын, туган җир образын, халыкның үткәнен, бүгенгесен чагылдырып, ул профессиональ музыка сәнгате шартларында милли-мәдәни, традицияләр өчен яңа офыклар ачып, классик форма «сурәтенә» яңа төсмерләр бирә. Әйе, сәнгатьнең нәфис гүзәл дөньясына безне композиторлар, башкаручылар алып керә. Җырлары, моңнары белән җаныбызны җылыталар, рухыбызга илаһи яктылык сирпиләр.

Композиторларның музыкасы, без яши торган бүгенге заман шикелле, каршылыкларның кискен бәрелешен хасил итә. Аңа көчле экспрессия хөкем сөрә, авазлар моңлана, әрни, сагышлана, өзгәләнә.

Әнвәр Шәрәфиевнең күпкырлы иҗаты һәрдаим үсеш кичерә: аның «Наз», «Чулпан йолдыз», «Сандугачкай» соңгы еллардагы иҗат җимешләре тупланган китаплары музыка сәнгатебезнең дә казанышлары булып саналырга хаклы һәм алар җөмһүриятебезнең югары бүләгенә – Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә һичшиксез лаек дип уйлыйм.

Раил СӘЙФУЛЛИН,
Татарстанның атказанган укытучысы.

Иң яхшы әсәргә бер мең евро тапшырыла

Проза белән кызыксынучы яшьләр өчен үз сәләтләрен сынап карау мөмкинлеге ачылды. «Ялкын» журналы, «Калеб» һәм Бөтендөнья татар яшьләре форумы белән берлектә, «Яңа татар прозасы» конкурсы оештыра.

– Бәйгедән бигрәк, бу – тәҗрибә уртаклашу урыны, лаборатория дип әйтергә мөмкин. Соңгы елларда проза язучылар артып киткәнлектән уйлап чыгарылган чара иде бу. Бүгенге көндә конкурска 24 кеше үзләренең әсәрләрен җибәрде. Күбесе – кызлар. Әсәрләрдә мәхәббәт, наркомания, тормыш-көнкүреш темасы яктыртылган. Без бәйгедә катнашучыларның яшен чикләмәскә булдык. Ай дәвамында алар белән дүрт остаз эшләргә тиеш. Яшь авторлар һәр көнне проза әсәре язачак. Остаз итеп Ркаил Зәйдулла, Нәбирә Гыйматдинова, Халисә Ширмән, Илдар Әбүзәров (соңгысы рус телендә иҗат итә) кебек язучыларны сайлап алдык. Шушы остаханәдә язган әсәрләреннән чыгып, иң яхшылары бәяләнәчәк. Җиңүчеләр май аенда Камал театры сәхнәсеннән игълан ителәчәк, – диде «Калеб» әгъзасы Йолдыз Миңнуллина.

Бөтендөнья татар яшьләре форумы җитәкчесе Тәбрис Яруллин әйткәнчә, проза язучыларны кызыксындырырга кирәк.

– Быел 1 мең евроны әлеге конкурста җиңүчегә тапшырачакбыз. Аны фин татарлары тапшырырга җыена. Соңгы вакытта яшьләр нинди әсәрләр укыйлар, дип сорыйлар. Миңа Ркаил Зәйдулла иң актив язучы булып тоела. Аның әсәрләрен укып барабыз. Шулай ук Марат Кәбиров бик актив. Сер түгел, кайбер язучылар, әсәрләрен рус теленә дә язсалар да, үзләрен татар язучысы итеп саныйлар. Мин моның белән килешәм, – ди ул.

«Ялкын» журналының баш мөхәррире Илназ Фазуллин язучыларны үстерүдә кызыксындыру чаралары кирәклеген ассызыклады.

– Әдәбиятта яңа исемнәр барлыкка килүгә бу бер җирлек булыр иде. Конкурста җиңүче авторның әсәре «Ялкын» журналында дөнья күрәчәк, – диде ул.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА.

Вәхшилек

19 март төнендә өч егет Татарстан Фәннәр академиясенең татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, Рәссамнар остаханәсе һәм Татарстанның сынлы сәнгать музее биналарының тәрәзәләрен ватып, диварларын кара буяу белән пычратып киткән.

Урам як камералар ярдәмендә бер тәүлек эчендә егетләрнең шәхесләре ачыклана. Хәзерге вакытта алар кулга алынган. Гаепләнүчеләр 20-25 яшьләр тирәсендә. Аларга «Хулиганлык» маддәсе буенча җинаять эше кузгатылды. Полиция хезмәткәрләре хәбәр иткәнчә, егетләр – «граффити» формаль булмаган хәрәкәте вәкилләре. Алар шәһәр урамнары буйлап үзләренә генә таныш символлар һәм язулар сызгалап йөри.

СӘЛАМӘТЛЕК

Адел Вафин: «Татарстанда пациентка аерым караш дип сөйләрлек булсын»

minzdrav.tatarstan.ru

– Бүген халыкка һәр өлкәнең эшенә бәя бирү мөмкинлеге тудырылган. Бары сыйфатлы эш күрсәтеп кенә халык хөрмәтен казанып була, – дигән иде Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Сәламәтлек саклау министрлыгының еллык йомгак коллегиясендә. Сәламәтлек саклау министры Адел Вафин үзе дә, пациентка медицина ярдәме күрсәткәндә культура дәрәҗәсен билгеләү максатыннан, корпоратив университет булдыру кирәклеген әйтә килде. Узган атнада «Корстон»да табиблар нәкъ менә корпоратив культура формалаштыру турында сөйләштеләр. Стратегик сессиягә Татарстанның дәүләт һәм хосусый медицина клиникаларыннан 300ләп белгеч җыелган иде.

– Без, медицина хезмәткәрләренең форумын уздырып, үзебезнең кыйммәтләрне билгеләдек. Пациент мәнфәгатьләре барысыннан да өстен. Сыйфатлы медицина ярдәме – команданың бердәм эш нәтиҗәсе ул. Төнлә, бәйрәм вакытларында ярдәм күрсәтү моделе көндезге эш тәртибеннән аерылырга тиеш түгел. Үзгәрешләр чыннан да кирәк, чөнки без зур хастаханәләрнең модернизация этабын үттек. Аннан соң пациентка йөз тоту юнәлеше билгеләнгән иде. Хәзер без корпоратив культура формалаштыру турында сөйләшәбез, – дигән Адел Вафин «Татар-информ»га.

Медицина өлкәсенең камилләшүе күз алдыбызда. Татарстанда заманча югары технологияләр ярдәмендә катлаулы операцияләр ясала, авылларда медицина объектларын яңартуга зур игътибар бирелә. Республикада белгечләрнең оешкан эше нәтиҗәсендә, үлүчеләр санын кимәтә алдылар, туучылар саны буенча Татарстан – Идел буе федераль округында лидер. Уртача яшәү озынлыгы арту да – мөһим күрсәткеч. 2006 елда ул 69 яшь булса, бүген инде 73 яшькә якынлашты. Әмма пациентка карата аерым караш, ягымлы мөгамәлә юк икән, нәтиҗәле эш турында сүз дә була алмый, дип саный министр.

– Сессиядә төрле учреждение җитәкчеләре белән нинди юнәлештә хәрәкәт итү, игътибарны нәрсәгә юнәлдерү турында сөйләшәчәкбез. Алга таба системалы эш көтелә. Халык та бу үзгәрешләрне сизеп, медицина учреждениеләре дустанә, уңайлы булганда, иң зур нәтиҗәгә ирешәчәкбез. Татарстанның сәламәтлек саклау өлкәсе бердәм команда рухында булырга тиеш, юкса нәтиҗәлелек түбән булачак. Безнең турыда бөтен дөньяда: «Картада шундый урын бар, анда пациентка аерым караш икән», – дип сөйләрлек булсын, – ди Адел Вафин.

«Бердәм Россия»нең Татарстан төбәге бүлегендә оештырылган медицина сыйфаты турындагы дискуссия барышында Адел Вафин сәламәтлек саклау системасын заманча лайнер белән чагыштырган иде. «Иң мөһиме – шул «лайнердагы пилотлар» тәҗрибәле булсын», – дип тә өстәде ул. Аның сүзләрен Казан дәүләт медицина университеты ректоры Алексей Созинов та хуплады. Корпоратив проект та Казан дәүләт медицина университеты, Югары медицина технологияләре буенча белем бирү үзәге белән берлектә гамәлгә ашырыла. Аны эшләүдә Россиядән иң яхшы белгечләр җәлеп ителәчәк.

Казан медицина университеты бу мәсьәләдә дөрес урынны биләп тора, чөнки корпорация агъзасы ул табиб яки урта медицина хезмәткәре генә түгел, ә студент та. Корпоратив культура дигәндә, без медицина университетында укый һәм эшли торган барлык кешене күздә тотабыз, алар җәмгысы алты меңгә якын. Университетта белем алучы студентлар киләчәктә эш мөнәсәбәтләренә кагылышлы барлык кагыйдәләрне өйрәнергә тиеш. Бу өлкәдә иң мөһиме – пациентка караш, – ди Алексей Созинов.

Бушлай тикшерен

Күпләр авырый башласалар, узар әле, дип өйдә дәвалана, медицина тикшерүе бик кыйммәткә төшә, чыгымлы дип саный. Баксаң, Татарстанда аны бушлай узу мөмкинлеге дә бар икән. Теркәлү урыны буенча сырхауханәләрдә генә түгел, Татарстанда эшләп килүче махсус сәламәтлек үзәкләрендә тикшеренергә була.

Биредә якынча бер сәгать эчендә буй озынлыгыңны, авырлыгыңны үлчиләр, йөрәккан тамырлары системасы торышын, кандагы холестерин, шикәр дәрәҗәсен, сулыш юлларын, күздәге кан басымын тикшерәләр, тешләрне карыйлар. Дөрес туклану һәм башкалар буенча киңәшләр бирәләр.

Табиблар мондый тикшерүләрне 18 яше тулган һәр кешегә елына бер тапкыр узарга киңәш итә. Татарстанда 2010 елдан бирле балалар өчен дә алты сәламәтлек үзәге эшләп килә. Аның өчесе Казанда урнашкан, калганнары Әлмәт, Чаллы, Түбән Камада эшли. Биредә медицина тикшерүеннән тыш, психолог белән киңәшләшергә, баланың физик яктан үсеш дәрәҗәсен билгеләргә дә була.

Сәламәтлек үзәкләрендә тикшерүләр узу бушлай, участок табибыннан юллама таләп ителми. Бары белгечләргә чиратка алдан язылырга, үзең белән паспорт һәм медицина полисын алырга гына кирәк. Сәламәтлек үзәкләренең тулы исемлеге, адреслары белән shahrikazan.com сайтында таныша аласыз.

НИЧӘ ЯШЬТӘ НИНДИ ТИКШЕРҮ УЗАРГА?

20-40 яшь

Электрокардиографик тикшерү (ЭКГ)	*5 елга 1 тапкыр*
Кан анализы	*ел саен*
Калкансыман бизне тикшертү	*ел саен*
Дерматологка күренү	*3 елга 1 тапкыр*
Флюорография	*ел саен*
Җенси юл белән иярә торган йогышлы авыруларга тикшеренү	*табиб кушуы буенча*

Шулай ук 30-40 яшьтән соң кан басымын даими күзәтеп тору, йөрәкне ишемия авыруына, эч һәм оча органнарын, эчәклекләрне тикшертү дә кирәк. Глаукома авыруын булдырмас өчен, күзләрне ешрак тикшертеп торсаң яхшы. 50 яшьтән соң бу тикшерүләрнең күбесе ел саен уздырыла, моңа пациентның хәленә карап, табиб кушуы буенча, башка анализлар да өстәлә. Хатын-кызларга гинекологка, маммологка күренеп торырга киңәш ителә. Ир-атларга онкомаркерга кан тапшыру авыруларны вакытында ачыкларга ярдәм итә.

СОРАУ-ҖАВАП

Казанда «Ашыгыч ярдәм» хезмәтеннән башка, тиз арада табиб кирәк булган очракта, тәүлек буе мөрәҗәгать итәргә мөмкин булган хастаханәләр бармы?

Айгизә САФИУЛЛИНА, Казан.

Сорауга Татарстанның сәламәтлек саклау министры **Адел ВАФИН** җавап бирә:

– Казанда атнасына җиде көн 24 сәгать эшли торган өч медицина учреждениесе бар: Авиатөзелеш районында 12нче шәһәр хастаханәсе, Яңа Савин районында 7нче шәһәр хастаханәсе һәм Республика клиник хастаханәсе.

КЕШЕДӘ БУ БИЛГЕЛӘР КҮЗӘТЕЛГӘНДӘ, КИЧЕКМӘСТӘН «АШЫГЫЧ ЯРДӘМ» ХЕЗМӘТЕ ЧАКЫРТЫРГА КИРӘК:



Сәхифәне **Эльвира МОЗАФФАР** әзерләде

Котлыйбыз!

«Казан» агросәнәгать паркының генераль директоры Олег Геннадьевич Власов Сезне ихлас күңелдән юбилеегыз белән тәбрик итәбез! Бетмәс-төкәнмәс егәр, рухи күтәренкелек, бәрәкәтле гомер, ныклы сәламәтлек һәм гаилә бәхете телибез. Тормышыгыз бөтен, сөенечле вакыйгаларга бай булсын!

Зур хөрмәт белән, **«Казан» агросәнәгать паркы коллективы.**

СОРАУ-ҖАВАП

Кышны бик суык булачак дип куркытканнар иде. Әмма алай булмады, хәтта быелгы елны тарихта иң җылы ел, диләр. Бу чынлап та шулаймы?

Азат НУРИЕВ,
Түбән Кама.

– Россия Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе, метеокүзәтүләр тарихында 2016 ел иң җылысы, – дип җиткерә. Бу хакта Россия Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе җитәкчесе Александр Фролов хезмәтнең коллегия утырышында хәбәр иткән. Дөньяда уртача еллык температура 10 ел эчендә 0,18 градуска күтәрелгән. Россиядә исә ул 2,5 тапкырга тизрәк үсә. Соңгы 10 ел эчендә температура үсеше Россиядә 0,45 градусны тәшкил итә. Җылынуның минуслары булган кебек үк, плюслары да бар. Бер яктан, җир эшкәртү мәйданнары киңәя, тискәре ягы – мәңгелек туңлык деградациясе биналар һәм торбаүткәргечләрнең җимерелүенә китерә.

Казанда капиталь ремонт ясалачак йортлар, объектларның исемлеген кайдан белергә була?

Нәҗия СӘЛАХОВА,
Казан.

– Шәһәрлеләр 2017 елда капиталь төзекләндерү программасына кертелгән йортлар, мәктәпләр, балалар бакчалары һәм яшүсмерләр клублары исемлеге белән www.kzn.ru/kapremont-2017 сайты аша таныша ала. Моннан кала, булектә бу елда төзекләндереләчәк ишегаллары һәм квартал эчендәге юллар, шулай ук урамнар исемлеге дә китерелгән.

«Себерке» бармы? Ә «Тишек»?!

Ломжа урамы тукталышында басып торам. Автобус көтмим, исәбем – юл аркылы чыгу. Кайчакта юл аша чыгар өчен дә озак көтәсең. Юлга терәлеп үк газета-журналлар сата торган киоск тора. Аларны хәзер Казанда сирәк очратам, газета-журнал укучылары сирәгәйгәннән-сирәгәя, күрәсең.

Шунда ыспай гына киенгән олы яшьтәге бер пар янәшәмә килеп басты.

– Карале, – диде ире, кычкырып ук. – Кара! Гәҗитләр саталар икән! Хәзер алып киләм, – дип, шул якка китте.

Хатыны белән мин, юл аша чыгасын онытып, аның артыннан карап калдык. Гәҗит дигәндә, күңелгә корт кергә бит, шуңа күрә яшел ут янса да, юл аркылы чыкмадым.

– «Себерке» бармы? «Себерке»! – дип гөрелдәде абзый, киоск төбенә килеп җиткәч.

Әшәке сүз ишетепме, абзыйның калын тавышына һәм кычкырып сөйләшүенә сәерсенепме, ярты тукталыш аның ягына борылып карады. Татарлар: «Бу киоск сатучысы белән әрләшә, ахрысы», – дип, колакларын аеруча да шомартты. «Себерке» булмады бугай, абзый кеше, тагын да катырак тавыш белән:

– Ә «Тишек»? – дип ярып салды.

Сатучы хатынның аңышып җитмәвеннәнме, абзый:

– «Тишек» килдеме соң бүген? – дип тавышланды.

Тукталыштагы татарларның күзе шар булды! Нәрсә соң бу дигәндәй, башларын чайкадылар. Мин аптырамадым, чөнки «Себерке» белән «Тишек»нең татар газеталары икәнен ишетеп белә идем. Менә нинди исемнәр бит ә, дип кызарганым да истә. Беренче тапкыр бу исемнәрне ишеткәч... Бер дә булмаса, шушындый үтә дә мәгънәле исемнәр куйсак, халыкны укымышлы итә алырбыз дип уйлагандыр инде аларны оештыручылар. Нишләтәсең, газета-журнал укучылар көннән-көн кими. Аларның санын арттыру өчен, төрле юлдан китеп карый журналистларыбыз. Дөньясы шундый дип аклансак кына инде... Тик: «Себерке», «Тишек», – дип, киоск янында кычкырып торган абзый гына нишләптер бик тә кызганыч булган иде ул көнне.

Айсылу ИМАМИЕВА.

Нур бөркүче ӘБИЕМ

Табигать-ана адәм балаларын кайгыртучанлык, мәрхәмәтлелек, наз кебек ихлас һәм җылы хисләргә сусый торган итеп яралткан. Ә шул җылылыкны кешеләрнең күңелләренә сирпү, тарату югарыдан әниләргә йөкләгән.

Әлеге язмамны безнең өчен газиз булган олы йөрәкле, безнең күңел дөньябызны җылытучы ак яулыклы ак әбиемә багышлыйм. Әниемнең әнисе Нәсимә Гайфетдинова – сабый чакта тиешенчә назга туенмаса да, үз балаларына күңел түрендәге саф хисләрдән мул өлеш чыгарган, мәрхәмәт тулы назлы карашын без оныкларыннан да кызганмаган зат.

1932 елның ямьле яз аенда Кукмара районының Зур Сәрдек авылында гаиләдә икенче бала булып дөньяга килә ул. Сабый чагы гаять авыр чорга туры килә шул әлеге буынның. Шул авырлыклар өстенә җиде яшьтән ятимлек ачысы да өстәлә, әтиләре дөнья куя. Берсеннән-берсе кечкенә дүрт бала белән ялгыз ана язмыш чатында кала. Шул көннән башлап сабыйлары да инде рәхимсез тормыш арбасын олыларча тарта башлый. Иртәдән кичкә кадәр басуда чүп утаулар, «уф алла» арбасы белән «караңгы тау» басуыннан кара әрем, кәҗә сакалы җыярга йөрүләр, салым түләү өчен Китәк базарына (Киров районы) май сатарга барулар, ат җигеп, ферма малларына су ташулар, яз җитүгә, Мәмәширдән кечкенә чана белән чәчүлек орлык ташулар, Кукмарага чиләк-көянтә белән йомырка илтүләр... Санап кына бетерә торганмы соң? Сугыш чоры елларында бу михнәтләр тагын да арта. Әбием сөйләгәннәрдән күңелгә иң уелып калганы шушы авыр эшләрне җигелеп башкару түгел, ә башкасы булды.

– Әтиле кешеләрнең чабаталары да күтәртмәле иде. Шул вакытта андыйларга и-и кызыгып карый торган идек инде. Безгә моны эшләүче булмады, шуңа күрә чәчүлек орлыгы ташыган вакытта чабаталарыбыз инде «чәчәк атар иде», – дип сөйли әбием.

Әйе, язмыш төрлечә сынаган әбиемне. Ә ул сынмаган, чөнки тырышлык, сабырлык, белемгә омтылыш кебек күркәм сыйфатларны Ходай аннан кызганмаган. Нәкъ менә шуңа да әбием авырлыклар алдында югалып калмый, Кукмарага килеп белем ала.

– Ул вакытта 150 сум акча түләп укыйсы иде. Беренче елны интернат булмады, кешегә фатирга кереп укыдык. Ә инде 9-10нчы классларда интернатта урын бирделәр, – дип искә төшерә әбием, үзенең ничек итеп «энә белән кое казуы»н искә алып.

Аннары үзе дә укытучылык эшенә керешеп китә. Сугыштан соңгы авыр чор, авыл мәктәпләрендә укытучылар җитми. Беренче елында Түбән Казаклар авылында башлангыч сыйныфларны укыта, аннары Байлангар, Вахит, Сәрдекбашта татар теле һәм ботаника фәннәреннән белем бирә. Бөтен күңелен биреп эшләргә өйрәнгән Нәсимәне балалар да ярата. Хәер, өлкәннәр арасында да хөрмәте була аның. Шуңа да авыл советы рәисе Динмөхәмәт абый Ишмөхәмәтов: «Авылларга йөреп эшләве авыр, әниеңә дә ярдәмче булырсың», – дип, аны үз авылында клуб мөдире итеп билгели. Биш ел буе башкара ул бу вазифаны.

– Анда да эш җиңел булмады, клуб суык, ягарга юк. Лампа яктысында эшләдек. Колхозда комсомол оешмасы бар, аны җитәкләүне дә миңа йөкләделәр. Комсомоллар күп, эш җитәрлек. Агроукулар, түгәрәкләр... Концертлар, театрлар белән күрше авылларга да күп йөрдек. «Галиябану»ны, «Беренче театр»ны куя идек. Ул вакытта агитаторлар булып та йөрдек. Кырдагы тракторчы, механизаторлар бик җылы каршы алып, «Тагын килегез!» – дип калалар иде. Кечкенәдән кул арасына кереп эшләгәнгә, бер нәрсәдән дә авырыксынмадык. Безнең әнинең дә эшләмәгән эше юк иде. Иртә-кич авыл советы һәм колхоз идарәсен җыештырды. Көндез кырда урак урды. Безне дә эшләгез, эшкә өйрәнерсез, эшләвегез минем өчен булса, өйрәнүегез үзегез өчен, дип өйрәтте, – дип хәтер яңарта әбием.

Тәрбияле, итагатьле булганга, кешеләр белән җиңел аралашкан, шул рәвешле аларның күз алдында үскән, хөрмәт казанган ул. Гаиләдә дүрт бала тәрбияләп үстергән, бүген инде тугыз оныкның яраткан әбисе. Кайчакларда, балачагына кайтып, башыннан үткән авырлыклар турында сөйли дә, гадәттәгечә: «Бүген тормышлар бик матур, барысына да шөкер итәргә кирәк. Дөньялар гына тыныч булсын», – дип куя.

Мин дә янәшәдә нур бөркүче әбиемә барлык балалары, оныклары исеменнән бәрәкәтле гомер телим. «Синдәй кешеләр күбрәк булса иде», – дим.

Айсылу МИНҺАҖЕВА,
Кукмара районы,
Зур Сәрдек авылы.

ФЕСТИВАЛЬ

Мария Рябова.

Автор фотолары

«Кырым язы» Казанда

«Казан» милли мәдәният үзәгендә Кырымның Россиягә кушылуына өч ел тулуга багышлап, Бөтенроссия акциясе кысаларында, студентларның «Кырым язы» фестивале узды.

Расиха ФӘИЗОВА

Фестиваль башланганчы ук, Татарстан студентлар лигасы рәисе Элькин Искәндәров:

– Без – илебезнең «Студентлар язы» кебек иң абруйлы иҗат фестиваленең чемпионнары, һәм үз дәрәҗәбезне-статусыбызны ел дәвамында мөмкин булган барлык сәхнәләрдә раслап киләбез, – дип, «Кырым язы»ның да шул югарылыкта узасына басым ясаган иде.

–Студентлар иҗат телендә Туган илгә мәхәббәтләрен белдерәләр. Без Ватан, мәхәббәт, гаделлек һәм Кырымны яратуыбыз турында җырлыйбыз бүген. Фестивальнең уникальлеген тояр өчен, чыгыш ясаучыларны тыңларга кирәк. Гәрчә бүген әле студентлар гына булсалар да, алар хәзердән үк профессионаллар белән бер. Аларны киләчәктә зур сәхнә көтә дип әйтә алабыз, – ди Элькин.

Фестивальнең «кырым»лыгы нәрсәдә чагыла соң, диярсез. Беренчедән, фестиваль башланганчы ук, тамашачылар Кырым рәссамнарының Ялта, Феодосия, Алушта, Симферополь кебек иң гүзәл урыннарны сурәтләгән пейзажлардан торган күргәзмәсе белән танышты (В.Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты оештырган). Кырым рухын, диңгездән искән тымызык җилне тамашачылар шул чагында ук тойды булса кирәк. Ә инде сәхнәгә Казан консерваториясе студенты, Венада, Киевта узган зур-зур халыкара бәйгеләрдә беренче, икенче дәрәҗә лауреат исемен яулаган Кырым татары Сервер Кадыйров; Кырым татарларының «Хайтарма» биюе белән чыккан хореография коллективы чыгышларын карагач, тамашачы үзен бөтенләй Кырымда кебек хис иткәндер. Иң кызыгы шунда – бу хисләр берьяклы гына түгел иде.

– Дөресен генә әйткәндә, Кырымнан читтә шундый чарада катнашырмын дип, башыма да китермәгән идем, безнең өчен өйгә кайтканнан ким булмады бу. Гомумән дә без, Кырымнан килгән студентлар, Казанда укуыбыз белән бик бәхетле. Биредә үзебезгә карата шуның кадәр дустанә мөнәсәбәт тоябыз. Халыклар үзара дус-тату Татарстанда, – ди Сервер.

Фестиваль кысаларында узган «Күптөрле Татарстан» фотокүргәзмәсе дә (Татарстан халыкларының яшьләр ассамблеясы) республикада яшәүче халыклар арасындагы дуслыкны тәкрарлый иде.

...Фестивальнең узганы сизелми дә калды. Алып баручылар интернет тавыш бирүдә 3200 (!) кеше катнашуын игълан итә. Һәм бераз көттереп кенә җиңүченең исеме дә билгеле була: КФУ студенты Мария Рябова! Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе урынбасары Римма Ратникова әйтмешли, Ватанга төрлечә хезмәт итеп була: чикләрне саклап та, эшең белән дә. Интеллектың, белемең белән дә аның киләчәген якынайтырга була. Шул ук вакытта Туган илне җыр белән дә данларга мөмкин — фестиваль нәкъ менә шуны күрсәтте дә. Римма Ратникова 2014 елгы Кырым вакыйгаларын искә төшереп узды.

– Ул чагында хәлләр катлаулы, Киев мәйданы күпмилләтле Кырымга күчәргә мөмкин иде. 27 февраль көнне иртә белән Дәүләт Советы депутатлары җыелып, Кырым халкына мөрәҗәгать кабул иттеләр: ничек кенә булса да тынычлыкны саклап калырга, хәрби конфликтны булдырмаска. Безне ишеттеләр. Безнең депутатлар, үзебезнең Кырым татарлары белән сөйләшүләр алып барырга дип, юлга кузгалды. Кырымлылар белән яхшы мөнәсәбәтләр урнаштыруда Президент Рөстәм Миңнеханов бик зур роль уйнады. 2014 елда Россия Президенты Владимир Путин депортацияләнгән Кырым халыкларын реабилитацияләү турында Указ кабул итте. Кырым татарлары да озак еллар җаннарында йөрткән киләймәдән тулысынча азат булды...

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе Анатолий Фомин әйтүенчә, «Кырым язы» тагын бер кат яшьләрнең моннан өч ел элек кабул ителгән карарны белүен, хуплавын күрсәтте.

Фестиваль тәмам. Ул дәвамлы булачак дип вәгъдә итә аны оештыручылар. Димәк, әле «Севастополь вальсы», Артек җырларының яңарасы көннәре алда.

Залда утыручылар арасында да: «Кырым – минем йөрәгемдә», – дип әйтерлек кешеләр шактый булгандыр. Шулай булмый ни – кем генә ял итмәгән соң Кырымда? Ә менә Кырымда 810нче аерым бригадада Диңгез пехотасында хезмәт иткән Азат Тимергалиевнең истәлекләре үзенә бер иде. Ул күбрәк җирнең һәр карышы совет сугышчыларының, бабаларыбызның каны, тире белән сугарылган Герой-шәһәр Севастопольне искә алды.

– Бу шәһәр рухландыра, ул үз илең өчен горурлык хисе уята, җаваплылык хисен арттыра. Анда чагында мин ике зур бәйрәмдә катнаштым. Беренчесе – Кырымның Россиягә кушылуының бер еллыгын бәйрәм итү, икенчесе – Җиңүнең 70 еллыгы һәм Хәрби Диңгез флоты көне. Бу – кырымлылар өчен ике иң зур бәйрәм. Урамнан барганда, безне: «Афәрин! Россия, Ур-ра!» – дип сәламлиләр иде. Бу хисләрне сүз белән генә аңлатып бетереп булмый. Хезмәт итү дәверендә Кырымның алга китешен күрдем. Шәһәр бер җирдә генә тормый – үсештә. Юллар төзекләндерелә, яңа балалар бакчалары, мәктәпләр ачыла. Без почетлы каравылда хезмәт иттек, бу чараларның бөтенесендә катнаштык, – ди ул.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ – БАШ МӨХӘРРИР ВАЗИФАСЫН БАШКАРУЧЫ Илсөяр Илфруз кызы Вәлиуллина.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – Расиха Габделбәр кызы Исмәгыйлова.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

Бу санның тиражы – 1668. Гомуми тираж – 6338.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 690. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77– 50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы